# НӘБИ ДӘҮЛИ

**Мәрьямия ГАЛЛӘМОВА, Әлки районы Базарлы Матак урта мәктәбе укытучысы**

**Максат.** Укучыларны якташыбыз, язучы Нәби Дәүлинең тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыру; сәнгатьле уку һәм бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү; әсәрләрен укуга кызыксыну уяту, якташыбыз иҗаты өйрәнгәндә патриотизм хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлау.** Нәби Дәүлинең портреты, китапларыннан төзелгән күргәзмә, тормыш юлы һәм иҗатына багышланган стенд, «Әлкием» җыры язылган аудиокассета, магнитофон, компьютер, «Мәгариф» журналы, 2008 ел, № 11 һ.б.

**Дәрес тибы.** Яңа материалны аңлату.

**Дәреснең эпиграфы:**

Чит якларны ят күрмәсәм,
Җаным илгә тартмас иде.
Каберем дә булмас иде,
Исемем дә кайтмас иде.
*Н.Дәүли*

**Дәрес барышы.**

**I. Оештыру.**

**II. Актуальләштерү.**

Укучылар, 2010 елның 1 июнендә күренекле шагыйрь һәм язучы, якташыбыз Нәби Дәүлинең тууына 100 ел тула. Шуны истә тотып, сыйныфтан тыш уку дәресендә Нәби Дәүлинең тормыш юлы һәм иҗаты белән танышырбыз.

**III. Яңа белем һәм күнекмәләр формалаштыру.**

**Укытучы.** Талантлы шагыйрь, язучы, якташыбыз Нәби Дәүли районыбызның ямьле табигатьле Мәүләшә авылында дөньяга килә. Әмма туган авылының чәчәкле болыннарында, яшел үләнле тау битләрендә тәгәрәп үсәргә насыйп булмый аңа. Аның язмышы Тукай язмышына охшаган. Ул да ятим үсә, тормыш авырлыгын күп күрә.

Тол калган әнисе, Ставрополь өлкәсендә яллы хезмәттә йөрүче Хәйрулла Дәүләтшинга кияүгә чыгып, өч баласы белән шул якларга күченеп китә.

**1 нче укучы.** Нәбигә ятимлекнең авырлыгын, ачлыкның газабын татырга, көтү көтәргә туры килә. Аның холкы шул елларда ук чыныга башлый. 11 яшьлек Нәби 1921 елда хәзерге Волгоград шәһәрендәге балалар колониясенә килеп эләгә. Биредә ул җидееллык мәктәптә укый. Аның тамагы тук, өсте бөтен була.

**Укытучы.** Тормыш егетнең рухын сыный, чыныктыра. Ул «Кызыл Октябрь» заводы каршында ФЗӨ мәктәбендә һөнәр үзләштерә. Аннары Донбасска китә, металл заводында тимерче булып эшли. Татар шахтерлары өчен чыгарыла торган «Пролетар» газетасында аның беренче шигырьләре басыла. Тора-бара ул үзе дә редакциянең әдәби хезмәткәре булып китә. Яшь авторның каләме чарлана, дөньяга карашы киңәя.

1931 — 1933 елларда ул Ерак Көнчыгыштагы чик буе гаскәрләрендә хезмәт итә.

**2 нче укучы.** Нәби Дәүли 1935 елда Казанга килә. «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре») газетасы редакциясендә әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире (җитәкчесе) булып эшли. Бер үк вакытта Казан дәүләт педагогия институтының кичке бүлегендә укый. Бу чорда Нәби Дәүли әдәбиятка ныклап аяк баса, шагыйрь буларак эзләнә, формалаша. Беренче китапларын чыгара.

**Укытучы.** 1937 — 1941 елларда Н.Дәүлинең «Бәхет», «Ал чәчәк», «Иртәнге җыр», «Уйлар», «Кырык шигырь» исемле шигырь һәм поэмалар җыентыклары басылып чыга. Шагыйрьнең 1937 елда «Бәхет» исемле беренче китабы, чыннан да, бәхетле булып чыга. Иҗатының башында ук Н.Дәүли зур өметләр уята һәм ул Хәсән Туфан тәкъдимнамәсе белән Язучылар берлегенә кабул ителә. Нәби Дәүли Бөек Ватан сугышына язучы буларак китә. Аның көчле пафос белән язылган шигырьләре дә халыкны дошманга каршы көрәшкә күтәрелергә чакыра. «Дошманнан үч алыгыз» исемле шигыре моңа мисал булып тора.

**3 нче укучы.** Нәби Дәүли 1941 елның август аенда әсирлеккә төшә. Аның өчен михнәтле, үкенечле, авыр тоткын тормышы башлана. Ул Германиягә озатыла, төрле концлагерьларда газап чигә.

1945 елның апрелендә, совет гаскәрләре Магдебург шәһәре янына якынлашып килгәндә, Н.Дәүли берничә иптәше белән лагерьдан кача һәм, фронт сызыгын үтеп, безнекеләргә кушыла. Сугышның соңгы айларында ул Совет Армиясе сафында солдат хезмәтен дәвам иттерә.

**4 нче укучы.** Н.Дәүли 1945 елның декабрендә генә Казанга кайта. Биредә аңа зур кимсетүләр күрергә туры килә. Янәсе «ышанычсыз», әсирлектә булган. Редакцияләргә ишек ябык булу сәбәпле, 1956 елга кадәр Казан шәһәренең сәнгать остаханәләрендә рәссамбизәүче булып эшли. (Ул рәсемне яхшы ясый торган була.)

**Укытучы.** Күп еллар укытучы булып эшләгән Дания Садриева истәлекләрендә Нәби Дәүли турында мондый юллар бар: «Нәби абый безнең өйдә еш кунак була иде. Аның Әүхәткә сөйләгәне әле дә хәтердә: «Әй, Әүхәт туган, туган җиремә кайткач, минем нинди авырлыклар күргәнне белсәң, үземнең дусларым миңа кул биреп күрешергә читенсенәләр, миңа дошман итеп карыйлар, каршы очрашасы булса, икенче якка борылып-борылып китәләр иде. Бу — минем өчен немец җәзасыннан да авыррак булды», — дип өзгәләнә, күзләреннән яшь тама иде дип яза.

**5 нче укучы** шагыйрьнең «Автопортрет» шигырен яттан сөйли.

**Укытучы.** 1958 елда Н.Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» дигән повесте, аннары «Җимерелгән бастион» романы (1965) дөнья күрә. Алар берничә тапкыр татар һәм рус телләрендә бик зур тираж белән басыла. Тиз арада халык күңелен яулаган автобиографик повесть Н.Дәүли биографиясендә яңа сәхифәне башлап җибәрә, аны популяр итә, илгә таныта.

Н.Дәүли 1970 — 1980 елларда актив иҗат эше белән шөгыльләнә. Курчак театры өчен пьесалар яза. «Айга очасым килә», «Бәхет җыры», «Җырлап узган җәй», «Гөлнур белән аю турында әкият» — шундыйлардан.

**6 нчы укучы.** Курчак театры өчен язылган бу пьесалар заманында яшь тамашачылар күңеленә хуш килә. 1960 елларда Н.Дәүлинең «Бәхет җыры» исемле пьесасы Бөтенроссия курчак театры смотрында I урынны ала. Пьесада сүз, кешенең авыр сынау юллары үтеп, үз бәхетен табуга ирешүе турында бара.

Болардан тыш, ул кечкенә күләмле хикәяләр, нәсер, юмореска, истәлек язмалары да иҗат итте. Аның балаларга атап язган «Каракай — йорт эте» (1976) исемле повестен, «Тамгалы бүре» хикәясен укучылар бик яратып укый.

**7 нче укучы** «Каракай — йорт эте» әсәренең кыскача эчтәлеге белән таныштыра.

**8 нче укучы** Н.Дәүлинең «Икмәк» шигырен яттан сөйли.

**Укытучы.** Нәби Дәүли һәр баланы белем юлына алып кергән, аңа туры юл күрсәткән, күзен ачкан Әлифба китабы турында мондый юллар язып калдырган: «Әлифба — бөек китап. Аңардан башка галим дә, әдип тә юк. Кеше ул китаптан башка дөм-сукыр». Бу — чыннан да шулай.

*(Слайдта кулына «Әлифба» китабы тоткан кыз бала рәсеме күрсәтелә. Аннары әдипнең төрле елларда басылган китаплары белән таныштырыла.)*

**Укытучы.** Нәби Дәүли иҗаты әле тиешенчә өйрәнелмәгән. Гали Халит, Зәки Нури, Шамил Маннапов, Салих Маннапов (Мөдәррис Вәлиев), Марсель Галиевнең язмаларыннан күпмедер мәгълүмат алырга мөмкин.

Алга таба Н.Дәүлинең хатлары белән таныштырыла, өзекләр китерелә.

*«Мөдәррис туганым!*

*...Синең «Казан утлары»нда чыккан мәкаләң... мине бер дә булмаган олы шатлык белән тетрәтте. Бу минем иҗатым турында беренче олы сүз.*

*Н.Дәүли, 4 июль, 1980».*

*«Хөрмәтле Салих туганым!*

*Мин синең «Тамыр тирәнлеген яфрак тоя» исемле китабыңны тагын бер кабат укып чыктым.*

*...Бу озын гомеремдә үзем турында шундый хат һәм кешелекле сүз ишетү миңа олы бәхет булды. Мин әле телгә алырлык кеше икәнмен...*

*Минем дошманнарымның кулларыннан коралларын ташларга мәҗбүр иттең, дип әйтсәм, һич ялгышмам.*

*Тагын бер кабат рәхмәт сиңа, туганым Салих.*

*Н.Дәүли, 16 октябрь, 1988».*

**Укытучы.** Нәби Дәүли үзенең якташлары Шамил Маннапов, Мөдәррис Вәлиев белән аралашып яши.

Шамил Маннаповның «Кайтмый еллар, кайталар җырлар» дигән бер мәкаләсендә әдипнең сүзләре китерелә: *«Беләсеңме, Мәннаф, (ул аңа шулай дәшә торган булган) мин туган ягыбызга багышлап җыр яздым бит әле. «Әлкием, әллием-бәллием». Музыкасын Зиннур Гыйбадуллин язды. Әйбәт килеп чыкты. Аны якташ җырчыбыз Мирсәет Сөнгатуллин җырлаячак. Бу җырны якташларыма алып кайтып тыңлатасы иде».*

Аудиоязмада «Әлкием» җыры тыңланыла.

Бу җыр якташларыбыз тарафыннан хәзер дә бик яратып җырлана.

**9 нчы укучы.** Н.Дәүли шигырьләренә Сара Садыйкова, Рөстәм Яхин, Александр Ключарев кебек күренекле композиторлар көй язды.

*(Н.Дәүлинең композитор Рөстәм Яхин белән төшкән рәсеме күрсәтелә.)*

**10 нчы укучы.** Н.Дәүли үзенең ятимлектә узган балачагы, үсмер еллары турында автобиографик роман язды. Ул «Язмышка юл», «Кояшка таба» дигән ике кисәктән тора. Аның күпчелек әсәрләре рус телендә дә нәшер ителде, башкорт, кыргыз, азербайҗан, казах, төрекмән телләренә дә тәрҗемә ителде. Хөкүмәтебез дә әдипнең хезмәтен югары бәяләде. Ул «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнде.

**IV. Йомгаклау.**

**Укытучы.** Нәби Дәүли Ватан алдында үзенең йөзе ак булуга, әсирлектә дошманга каршы яшерен көрәшүләре турындагы фактларның кайчан да булса илгә кайтып ирешәчәгенә ышанып яшәгән. Шулар хакында ул үзенең үлемсез әсәрләрендә дә яза, әмма аларның әсирлектәге батырлыгын, гаепсез булуын күрсәтүче рәсми документлар табылмый. Андый документ язучы үлгәч кенә, тууына 80 ел тулган көннәрдә генә Казанга кайта. Казанның Актерлар йортында Нәби Дәүлинең 80 еллыгына багышлап үткәрелгән тантаналы кичәдә хәрби комиссариат вәкиле юбилярның хатыны Наҗия апага Н.Дәүлинең соңарып килгән медален тапшыра.

Районыбызда Нәби Дәүлинең исемен мәңгеләштерү уңаеннан күп кенә эшләр алып барыла. Базарлы Матак авылындагы гимназия Нәби Дәүли исемен йөртә. Базарлы Матак авылындагы бер урамга да аның исеме бирелде. Алпар урта мәктәбендә Н.Дәүли музее эшли.

**Өй эше.** Н.Дәүлинең әсәрләрен укырга.

Дәрестә актив катнашкан укучыларга билгеләр куела.